Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Иске Дөреш авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Иске Дөреш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Г.Тукай, Ленин, Яшьләр урамнарында сууткәргеч челтәрен ремонтлау)»;

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 19 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Иске Дөреш авылында гражданнар җыены карарына:

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Г.Тукай, Ленин, Яшьләр урамнарында сууткәргеч челтәрен ремонтлау)».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иске Дөреш авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков

Совет Стародрюшского сельского поселения